**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**

**_________________ И.Г.Һадиуллин**
**«___» _________ 2023 нче ел**

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең татар укучылары өчен 2024 нче елда туган (татар) әдәбияттан бердәм республика имтиханын уздыру үзенчәлекләре (спецификация)

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**1. Имтихан эше вазыйфасы**

Бердәм республика имтиханы (алга таба – БРИ) стандартлаштырылган биремнәр (контроль бәяләү материаллары) ярдәмендә урта (гомуми) белем бирү дәүләт программаларын үзләштергән укучыларның әзерлек сыйфатын объектив бәяләүне күздә тота.

Контроль бәяләү материаллары урта мәктәпне тәмамлаучы укучыларның татар әдәбиятыннан гомуми белем дәрәҗәсен билгеләү мөмкинлеген бирә.

**2. Имтихан эшенең эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге түбәндәге документларга нигезләнеп билгеләнә:

1. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: Мәгариф, 2010.
2. Рус телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) (1 – 11 сыйныфлар өчен) /Ф.Ф.Хәсәнова // http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_1128127.pdf

**3. Имтихан эшенең төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү принциплары**

Имтихан эшенең төзелеше һәм эчтәлеге урта мәктәпне тәмамлау һәм югары, урта һөнәри белем бирү уку йортларына керү вакытында укучыларның белем дәрәҗәсен объектив бәяләү мөмкинлеген бирә.

Татар әдәбиятыннан бердәм дәүләт имтиханын уздыруның берничә еллык тәҗрибәсе аның төзелеше һәм эчтәлегенең максатка ярашлы, оптималь булуын күрсәтте. Имтихан эшенең формасы һәм төзелеше, биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе урта белем бирү мәктәпләрендә татар әдәбияты курсының төрле баскычларын, бүлекләрен яктырта. Аның эчтәлеге укучыларның татар әдәбиятыннан теоретик һәм гамәли белем дәрәҗәсен, күнекмәләрен бәяләргә мөмкинлек бирә.

Шул рәвешле татар әдәбиятыннан бердәм дәүләт имтиханы имтихан тапшыручылардан аналитик фикерләүне, әсәрне анализлау юлларын камилләштерүне, төрле әдәби чор һәм фактларны чагыштырып бәяләү күнекмәләрен активлаштыруны таләп итә.

**4. Имтихан эшенең төзелеше**

Укучы, әдәбияттан имтиханга әзерләнү барышында, урта (тулы) гомуми мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә билгеләнгән материалны, уку дәверендә әлеге предметтан үзләштергән-өйрәнгәннәрен кабатларга тиеш.

2024 нче елгы бердәм республика имтиханыннан контроль бәяләү материаллары укучының белем дәрәҗәсен төрле яклап билгеләүче <u>өч бүлектән</u> тора.

Беренче һәм икенче бүлектә мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә билгеләнгән әсәрләргә анализ ясау тәкъдим ителә.

Бу бүлекләрдә укучының әдәби әсәрләрнең эчтәлегенә, төзелешенә караган төп төшенчәләрне, сыйфатларны (темасын һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны,

сюжет һәм сюжет элементларын, образлар системасын, әдәби алымнарны, тел-сурәтләү чараларын һ.б.) дөрес билгели белү дәрәҗәсе тикшерелә; тәкъдим ителгән әсәрнең аерым үзенчәлекләрен башка әсәрләр белән бәйләнештә аңлата белү мөмкинлекләре барлана.

Беренче һәм икенче бүлек әдәби әсәрне эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан тулысынча үзләштерүгә юнәлдерелгән. Анализ өчен тәкъдим ителгән текстлар укучының әсәрнең сюжетын белү дәрәҗәсен ачыклаудан бигрәк, жанр үзенчәлегеннән чыгып, әдәби текстка анализ ясау мөмкинлекләрен билгеләүгә йөз тота.

Беренче һәм икенче бүлекләрдәге соңгы бирем әдәби контекстка юнәлтелә: анализ өчен алынган өзектә күтәрелгән тема-проблемаларның уку дәверендә өйрәнелгән башка әсәрләр белән аваздашлыгы, охшашлыгы билгеләнә, әдәбият дәресләрендә өйрәнелгәннәр башка фәннәрдән алган белемнәр белән дә бәйләнештә карала ала. Шул рәвешле тикшереләчәк материал эчтәлеге ягыннан тагын да баетыла.

Эшнең соңгы (өченче) бүлегендә укучының билгеле бер әдәби әсәр (әсәрләр) турында тупланма фикере, билгеләнгән үзенчәлекне аңлата белү сәләте тикшерелә.

Эпик (яки драма) әсәрдән алынган өзеккә анализ ясау каралган 1 нче бүлектә кыска җавапны таләп иткән 7 һәм чикләнгән күләмдәге җавап соралган 2 бирем тәкъдим ителә.

2 нче бүлектә укучыга лирик әсәргә анализ ясау өчен 7 бирем тәкъдим ителә. Аларның бишесенә – кыска, икесенә чикләнгән күләмдәге (5-10 җөмлә) җавап язу күздә тотыла.

Эшнең мондый эзлеклелектә оештырылуы әсәрдән алынган өзекнең тексттагы ролен, урынын, әсәрнең сюжет-композицион, тема-проблема, тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләү, укучының аларга карата үз фикерен җиткерә алу мөмкинлеген бирә.

3 нче бүлектә укучыларга билгеләнгән әсәрдәге яки әдипләр иҗатындагы аерым үзенчәлекләрне (образлар бирелешен, тема-проблемаларны, алымнарны) ачыклауга йөз тоткан 3 тема тәкъдим ителә. Имтихан эшендә бу сорауларның берсенә киңәйтелгән җавап язу сорала. Сораулар әдәби-тарихи процесстагы төп чорларны үз эченә ала һәм:

*1 нче сорау* – Борынгы, Урта гасырлар татар әдәбияты үрнәкләре һәм XIX гасырда иҗат иткән әдипләрнең әсәрләреннән;

*2 нче сорау* – XX йөз башында иҗат иткән классикларның әсәрләреннән;

*3 нче сорау* – XX гасырда (1917 нче елдан соң) язылган әсәрләрдән чыгып төзелә.

Укучы өч сорауның берсен генә сайлап ала һәм, үз дәлилләре белән баетып, шуңа җавап яза.

Проблемалы сораулар укучының тормышны танып-белү, логик һәм иҗади фикерләү, фикерен дәлилли алу дәрәҗәсен ачарга ярдәм итә, аңа әдәби очерк формасында үз мөнәсәбәтен җиткерү мөмкинлеген бирә.

Тикшеренүләр шуны күрсәтә: мондый төр эшләрне башкару укучыдан танып белүдә мөстәкыйльлекне таләп итә, сәнгатьнең бер төре һәм укыту фәне буларак,

матур әдәбиятның үзенчәлеген ачарга ярдәм итә. Әдәбиятның төп максатына – югары әдәби зәвыклы һәм әхлакый-мәдәни, рухи яктан камил шәхес тәрбияләүгә йөз тота.

Түбәндә имтихан эше биремнәренең өлешләргә бүленешен схематик формада чагылдырган таблица тәкъдим ителә.

**Имтихан эшендәге биремнәрнең бүлекләргә бүленеше**

*1 нче таблица*

| **Эшнең бүлекләре** | **Биремнең төре** | **Бирем-нәрнең саны** | **Беренчел максималь балл** | **Тулы эш өчен бирелгән максималь баллның беренчел эшкә карата проценты (=39%)** |
|---|---|---|---|---|
| 1 нче бүлек | Кыска җаваплы | 7 | 7 | 36% |
| | Чикләнгән күләмдәге җаваплы | 2 | 9 | |
| 2 нче бүлек | Кыска җаваплы | 5 | 5 | 31% |
| | Чикләнгән күләмдәге җаваплы | 2 | 9 | |
| 3 нче бүлек | Тулы җаваплы | 1 | 15 | 33% |
| | **Барлыгы:** | **17** | **45** | **100%** |

Бердәм республика имтиханы өчен тәкъдим ителгән әлеге модель укучыларның белемен ике баскычта (мәктәп программасы һәм профильле программа) тикшерергә мөмкинлек бирә. Төзелеше ягыннан ике бүлек тә логик эзлеклелектә төзелгән: ул катлаулылык дәрәҗәсенә мөнәсәбәттә гадидән өлешчә катлаулыга (1 бүлек: 1-7, 8-9; 2 бүлек: 10-14, 15-16) таба үсә бара. 3 бүлеккә тәкъдим ителгән бирем катлаулы материалга йөз тота. Мондый эзлеклелек укучыларының татар әдәбиятыннан алган белемен бәяләү белән бергә, шушы профильдәге уку йортларына керү мөмкинлекләрен билгеләүне дә максат итеп куя.

### 5. Эчтәлекнең, элементларына карап, биремнәргә бүленеше

Әдәбияттан имтихан эше буларак тәкъдим ителгән материал эчтәлек ягыннан 6 өлешкә (2024 нче елда татар әдәбиятыннан уздырылачак бердәм республика имтиханының контроль бәяләү материалларын (КБМ) төзү өчен тәкъдим ителгән кодификатордан карагыз) бүленгән. Кодификатордагы “Әдәбият теориясеннән һәм тарихыннан белешмә” өлешенә нигезләнеп, КБМ га аерым теоретик төшенчә һәм терминнар кертелә. Калган 5 бүлектә әдәби барыштагы аерым әдәби-тарихи чорларга кагылышлы әдәби әсәрләр урын ала:

- Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятыннан;
- XIX йөзгә караган әдәбияттан;

- XX йөз башы татар әдәбиятыннан;
- XX йөз әдәбиятыннан (1917 нче елдан соң);
- XX йөзнең соңгы чирегенә караган әдәбияттан.

Имтихан эшенең һәр вариантында өч блокның эчтәлеген чагылдырган биремнәр урын ала:

1. Борынгы, Урта гасырлар әдәбияты һәм XIX йөз әдәбияты;
2. XX йөз башы татар әдәбияты;
3. XX гасыр әдәбияты.

Сорауларның саны материалның мәктәптә өйрәнелү дәрәҗәсенә, күләменә карап билгеләнә.

Түбәндә, 2 нче таблицада, 5 бүлектә чагылыш тапкан әдәбият материалының биремнәрдә якынча бүленеше күрсәтелә.

*2 нче таблица*

| № | Бүлек | якынча бүленеше (% ларда) |
|---|---|---|
| 1. | Борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбиятыннан | 0 –10 % |
| 2. | XIX йөз әдәбиятыннан | 0 – 10 % |
| 3. | XX йөз башына караган әдәбияттан | 15 – 35 % |
| 4. | XX йөзгә караган әдәбияттан | 20 – 35 % |
| 5. | XX гасырның соңгы чирегенә караган әдәбияттан | 0 –15 % |

Эшнең беренче һәм икенче бүлекләренә караган биремнәр, алда әйтелгәнчә, укучының төрле әдәби төрләргә (эпик, драматик яисә лирик) караган әсәрләргә анализ ясый белүен тикшерү максатыннан кертелә. Әдәби әсәрләрнең укучыларга яхшы таныш булганнары, эчтәлек һәм форма ягыннан имтихан өчен уңышлылары сайлап алына.

Анализ өчен алынган текстлар әдәбиятның төрле чорларын колачлый: XIX йөз әдәбияты – XX йөз башы – XX йөз (1917 нче елдан соң) әдәбияты. (Имтихан эшенә тәкъдим ителгән вариантларның беренче һәм икенче бүлекләрендәге әдәби текстлар, эшнең туплануына карап, әдәби процессның төрле этапларын чагылдыра).

3 нче бүлектәге биремне (әдәби әсәр турындагы проблемалы сорауга язмача җавап бирү) үтәү өчен, укучыларга өч чорга (урта гасырлар һәм XIX йөз татар әдәбиятына, XX йөз башына, XX йөзгә) караган сорауларның берсенә генә җавап бирү мөмкинлеге бирелә.

Имтихан эшенең эчтәлеге һәм төзелеше укучының әдәбияттан алган белемнәрен (әдәбият тарихы һәм теориясе) бәяләргә һәм предмет буенча эшли алу сәләтен билгеләргә мөмкинлек бирә:

– әдәби текстка төр һәм җанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белүен;
– әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алуын;
– төрле характерда үз фикерен җиткерә алуын;

– әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгели алуын, геройга характеристика бирү мөмкинлеген;

– әдәби әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгели алуын;

– әсәрләргә язма интерпретация (шәрехләмә) бирә алуын;

– әдәби факт һәм күренешләрне чагыштыра белүен;

– әсәрдә автор позициясен билгели алуын;

– укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә, сочинение яза алуын.

Санап үтелгәннәрне, төркемнәргә туплап, таблицада бирергә мөмкин.

## 6. Биремнең катлаулылык дәрәҗәсенә карап бүленеше

Имтихан эшенә катлаулылыгы ягыннан өч төрле бирем тәкъдим ителә: 1 нче һәм 2 нче бүлектә бирелгән 12 (1 – 7; 10 – 14) бирем мәктәп программасы материалыннан алына, 4 бирем (8 – 9; 14 – 15) өлешчә катлауландырылган, 3 нче бүлектәге бирем катлаулы бирем дип санала. Имтихан бирүчегә анда тәкъдим ителгән өч биремнең **б е р с е н г е н ә** сайлап алу һәм шуңа җавап язу мөмкинлеге бирелә. Бу очракта имтихан тапшыручы, мөстәкыйль рәвештә, әдәби темага эчтәлеге белән туры килгән, мәгънәви яктан эзлекле текст яза белүен күрсәтергә тиеш.

**Биремнең катлаулылыгы ягыннан бүленеше**

*3 нче таблица*

| **Катлаулылык дәрәҗәсе** | **Биремнәрнең номеры** | **Биремнәрнең төре** | **Биремнәрнең саны** | **Беренчел максималь балл** | **Тулы эш өчен бирелгән максималь баллның беренчел эшкә карата проценты (=39%)** |
|---|---|---|---|---|---|
| База өлеше | 1 – 7; 10 – 14 | кыска җаваплы | 12 | 12 | 29 % |
| Өлешчә катлауландырылган | 8 – 9; 14 – 15 | тулы җаваплы | 4 | 16 | 38 % |
| Катлаулы | 17.1. – 17.3. | тулы җаваплы | 1 | 14 | 33 % |
| **Барлыгы:** | | | **17** | **42** | **100 %** |

## 7. Аерым биремнәрне һәм тулаем эшне бәяләү.

Имтихан эшенең 1 нче һәм 2 нче бүлекләрендәге кыска җавапны таләп итүче сорауга бирелгән дөрес җавап **1 балл** белән бәяләнә.

Биремгә чикле күләмдәге текст белән җавап язылган эшне экспертлар бәяли. Бәяләү барышында “фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы” һәм “сөйләм нормаларына туры килүе” критерийлары үзәккә куела, сөйләм ягыннан оештырылышына игътибар ителә. Шулай итеп, 5-10 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәргә һәр дөрес җавабы **дүртәр балл** белән бәяләнә.

Чагыштырма планда 5-10 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәр “тәкъдим ителгән әсәрнең әдәби контекстка кертелүе һәм җавапның

нигезләнгән булуы” критерие нигезендә бәяләнә. Җавапны тикшерү барышында беренче критерий буенча 0 балл куелса, җавап икенче критерий нигезендә тикшерелеп тормый. Дөрес җавап язган очракта, бу биремнәргә укучы һәр дөрес җавабы өчен **дүртәр балл** ала.

Өченче бүлектәге сочинение форматында киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрнең берсен, сайлап алып, дөрес башкарган очракта, биш критерий нигезендә **14 балл** куела. Әгәр имтихан бирүче беренче критерий буенча (эчтәлек ягы) **0 балл** алса, өченче өлештәге бирем үтәлмәгән булып санала.

Имтихан нәтиҗәләре, шушы профильдәге урта һәм югары уку йортларына керү баллары булып та саналганлыктан, 100 баллык шкала белән бәяләнә.

Әгәр укучы иң түбән (минималь) баллдан да түбән билге алмаса, татар әдәбиятыннан бердәм республика имтиханының нәтиҗәсе таныклыгына куела.

**8. Имтихан эшен башкару өчен 210 минут вакыт бирелә.**

Эшнең беренче һәм икенче бүлекләрен башкару өчен (эпик яки драма әсәре алынган өзеккә анализ ясауга) – 2 сәгать, өченче бүлекне үтәүгә калган вакыт күздә тотыла.

**9. Имтихан эшендәге үзгәрешләр.**

2023 нчы ел белән чагыштырганда, 2024 нче елгы татар әдәбиятыннан имтихан сорауларында үзгәрешләр юк.

Кушымта

# 2024 нче елда татар әдәбиятыннан уздырылачак бердәм республика имтиханының гомуми планы

Биремнәрнең язмада һәм җавап бланкындагы

**Катлаулылыгы ягыннан:**
**Б** – база белем (үтәлеше якынча 60 % – 90 %);
**Ө** – өлешчә катлауландырылган ( 40 % – 60 %);
**К** – катлаулы (40 % тан кимрәк).

Имтихан эшенең планына белемне тикшерү өчен биремнәр туплана. Белем дәрәҗәсе кодификаторга тупланган эчтәлектән чыгып кына тикшерелә. Татар мәктәпләре һәм гимназияләре укучылары өчен тәкъдим ителгән кодификатордагы эчтәлекне 2 блокка тупларга мөмкин.

**1 нче блок** эпик әсәрләрдән алынган 3.2, 3.3, 3.4, 3.5, 4.1, 4.2, 4.3, 4.4, 4.5, 5.1, 5.4, 5.5, 5.12, 5.13, 5.14, 5.15, 5.16, 6.1 һәм драма әсәрләреннән алынган 4.9, 4.10, 4.11, 5.3, 5.17, 6.3 өзекләрдән тора.

**2 нче блокка** XX йөздә иҗат ителгән шигъри әсәрләр кертелгән: 4.6, 4.7, 4.8, 5.2, 5.6, 5.7, 5.8, 5.9, 5.10, 5.11, 5.18, 6.2.

| **№** | **Биремнәр-нең номеры** | **Белемнәр-не тикшерү коды** | **Кодификатор буенча эчтәлек элементларын тикшерү коды** | **Биремнәр нең катлаулы лык дәрәҗәсе** | **Биремне үтәгән өчен максимал ь балл** | **Биремне үтәү өчен бирелгә н якынча вакыт (минут-ларда)** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 БҮЛЕК | | | | | | |
| 1 | 1 | 1.1 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 2 | 2 | 1.1 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 3 | 3 | 1.2 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 4 | 4 | 1.2 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 5 | 5 | 1.2 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 6 | 6 | 1.2 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 7 | 7 | 1.2 | 1 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 8 | 8 | 1.3 | 1 нче блок | Ө | 4 | 21 |
| 9 | 9 | 1.4 | 1 нче блок | Ө | 5 | 21 |
| 2 БҮЛЕК | | | | | | |
| 10 | 10 | 2.1 | 2 нче блок (5.4) | Б | 1 | 3 |
| 11 | 11 | 2.1 | 2 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 12 | 12 | 2.1 | 2 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 13 | 13 | 2.1 | 2 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 14 | 14 | 2.1 | 2 нче блок | Б | 1 | 3 |
| 15 | 15 | 2.2 | 2 нче блок | Ө | 4 | 21 |
| 16 | 16 | 2.3 | 2 нче блок | Ө | 5 | 21 |

| № | Биремнәр-нең номеры | Белемнәр-не тикшерү коды | Кодификатор буенча эчтәлек элементларын тикшерү коды | Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремне үтәгән өчен максималь балл | Биремне үтәү өчен бирелгән якынча вакыт (минут-ларда) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 БҮЛЕК | | | | | | |
| 17 | 17.1 | 3.0 | Урта гасыр әдәбиятына яки XIX йөзгә караган бер әсәрдән | К | 15 | 120 |
| 18 | 17.2 | | XX йөз башы әдәбиятына караган әсәрдән | | | |
| 19 | 17.3 | | XX йөз әдәбиятына караган әсәрдән | | | |
| Биремнәрнең гомуми саны – 17.<br>Катлаулылык дәрәҗәсенә карап: б. – 12, өлешчә катлауландырылган – 4, катлаулы – 1.<br>Эшкә максималь балл – 42.<br>Имтихан эшен башкару вакыт - 210 минут | | | | | | |